# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **23.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Урманай авыл җирлеге
составына керүче Урманай авылында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Урманай авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2020 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

2.1. Урманай авылында юлларны кардан чистарту,
2.2. Урманай авылы Г. Галиев һәм Татарстан урамнарында асфальт-бетон өслекле юллардагы чокырларны ямау(килешү буенча сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А й. (Башкарма комитет администрациясе бинасы);
-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 27а й. (Урманай авылы мәдәният йорты).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урманай авыл җирлеге Башлыгы: А.И.Закиров